| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НИЖНЕКУЮКСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br><br>ул. Татарстан, д.71а, село Нижний Куюк, 422741<br>Тел.: (8-84369) 33-2-47; факс: 33-2-47 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>Татарстан урамы., 71а йорты, Түбән Көек авылы, 422741<br>Тел.: (8-84369) 33-2-47; факс: 33-2-47 |
|---|---|---|


# КАРАР

“22” декабрь 2021 ел. № 23

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 30 июлендә 15 нче номерлы карары белән кабул ителгән “Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 18 сентябрендәге 1574 нче номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү таләпләренә үзгәрешләр кертү турында» карары, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 30 июлендәге 15 нче номерлы карары белән расланган «Капиталь төзелеш объектларына рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламент”ына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2.16.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2.16.1 Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителә:
а) хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алу;
б) хезмәтләр күрсәтү турында сорау бирү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органга (оешмага), күпфункцияле үзәккә (алга таба – соратып алу) язылу;
в) соратып алу;
г) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган соратып алуны һәм башка документларны кабул итү һәм теркәү;
д) хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу;
е) запросны үтәү барышы турында мәгълүмат алу;
ж) хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашыру;
з) орган (оешма), органның (оешманың) вазыйфаи затына яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү;
и) хезмәт күрсәтүнең административ регламентында мөрәҗәгать итүченең билгеләренә туры килә торган хезмәт күрсәтү максатыннан, мөрәҗәгать итүчедән

анкета алу (мөрәҗәгать итүчегә сораулар исемлеген һәм күрсәтелгән сорауларга җаваплар вариантларының тулы исемлеген күрсәтү) ;
к) мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган хезмәт күрсәтү вариантын күрсәтү».

1.2. 2.16.3 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.16.3. Кабул итүгә язылу орган (оешма), күп функцияле үзәк, билгеләнгән тәртиптә бердәм портал, хезмәт күрсәтү порталлары яки рәсми сайтлар белән интеграцияләнгән башка мәгълүмат системасы аша башкарыла ала.»;

1.3.2.16.3 пунктының унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Язуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчедән, хезмәт күрсәтү тәртибен, кабул итү максатын күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш, бүтән гамәлләр кылуны, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүне таләп итү тыела.».

2. Әлеге карарның 1.2. һәм 1.3. пунктлары 2022 нче елның 22 мартыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Көек авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе — Галиәхмәтов Д.М.